**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

2021 елның 24 маендагы 1279 нчы номерлы карары

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2013 елның 24 декабрендәге 11787 нче номерлы**
**«Эшкә сәләтсез яки эшкә сәләтләре чикле гражданнарны**
**опекага алу һәм попечительлек өлкәсендә**
**административ регламентларны раслау**
**турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2016 елның 19 декабрендәге 433-ФЗ номерлы «“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»гы, 2017 елның 29 декабрендәге 479-ФЗ номерлы «“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы федераль законга гариза бирүче тарафыннан бердәм гариза бирү юлы белән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләрдә берничә дәүләт (муниципаль) хезмәтен күрсәтү мөмкинлеген беркетү өлешендә үзгәрешләр кертү турында»гы федераль законнар нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 24 декабрендәге 11787 нче номерлы «Эшкә сәләтсез яки эшкә сәләтләре чикле гражданнарны опекага алу һәм попечительлек өлкәсендә административ регламентларны раслау турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 30 декабрендәге 7616 нчы номерлы, 2016 елның 1 июлендәге 2644 нче номерлы, 2017 елның 5 июнендәге 2094 нче номерлы, 2018 елның 25 гыйнварындагы 204 нче номерлы, 2019 елның 29 августындагы 3027 нче номерлы, 2020 елның 29 маендагы 1514 нче номерлы, 2021 елның 11 февралендәге 315 нче номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1-7, 9-13 нче номерлы кушымталардагы 1.3 пунктта «Опека һәм попечительлек органының кабул итү графигы: дүшәмбе – 14.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, пәнҗешәмбе – 9.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр» сүзләрен «Опека һәм попечительлек органнары шимбә, якшәмбе һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәреннән кала көн саен эшли. Кабул итү графигы опека һәм попечительлек органының эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 1, 3-9, 11, 12, 13 нче номерлы кушымталардагы 1.3 пунктта «балигъ булмаган баланың теркәлү урыны буенча» сүзләрен «тәрбиядәге баланың яшәү урыны буенча» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 1-13 нче номерлы кушымталарда 5.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«- дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогын яисә тәртибен бозу;

- федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса, дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору. Әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелгән күпфункцияле үзәккә 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса, бу очракта гариза бирүче күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирә ала»;

1.4. 1, 2, 11 нче номерлы кушымталарда «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең эчтәлеге» графасының 2.6 пунктында «яшәү урыныннан йорт (фатирлар) кенәгәсеннән өземтә яисә торак урыннан файдалану хокукын яки торак урынына милек хокукын раслый торган башка документ һәм яшәү урыныннан шәхси финанс счеты күчермәсе» сүзләрен

«яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында мәгълүматлар яисә торак урыннан файдалану хокукын яки торак урынына милек хокукын раслый торган документ» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 1, 2, 11 нче номерлы кушымталардагы 3.3.2 пунктта «яшәү урыныннан йорт (фатирлар) кенәгәсеннән өземтә яисә торак урыннан файдалану хокукын яки торак урынына милек хокукын раслый торган башка документ һәм яшәү урыныннан шәхси финанс счеты күчермәсе» сүзләрен «яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында мәгълүматлар яисә торак урыннан файдалану хокукын яки торак урынына милек хокукын раслый торган документ» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 2 нче номерлы кушымтада:

1.6.1. 1.3 пунктта «балигъ булмаган баланың теркәлү урыны буенча» сүзләрен «гариза бирүченең яшәү урыны буенча» сүзләренә алмаштырырга;

1.6.2. «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең эчтәлеге» графасының 2.5 пунктындагы 6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бирергә «Чит дәүләтнең вәкаләтле органнары тарафыннан бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариуста таныкланган рус теленә тәрҗемәсе (әгәр опекун булырга теләк белдергән гражданин өйләнгән яки кияүдә булса)»;

1.6.3. «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең эчтәлеге» графасының 2.5 пунктында егерме җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә: «- чит дәүләтнең вәкаләтле органнары тарафыннан бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсен һәм аның нотариуста таныкланган рус теленә тәрҗемәсен (әгәр опекун булырга теләк белдергән гражданин өйләнгән яки кияүдә булса)»;

1.7. 3, 5 нче номерлы кушымталарда:

1.7.1. «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең эчтәлеге» графасының 2.6 пунктында «Торак-коммуналь хуҗалыгы идарәче компаниядән яисә Торак милекчеләре ширкәтеннән йорт (фатирлар) кенәгәсеннән өземтә» сүзләрен «Яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында мәгълүматлар

яисә торак урыннан файдалану хокукын яки торак урынына милек хокукын раслый торган документ» сүзләренә алмаштырырга;

1.7.2. 3.3.1 пунктта «йорт (фатирлар) кенәгәсеннән өземтә (Торак-коммуналь хуҗалыгы идарәче компаниясе яисә Торак милекчеләре ширкәте)» сүзләрен «яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында мәгълүматлар яисә торак урыннан файдалану хокукын яки торак урынына милек хокукын раслый торган документ» сүзләренә алмаштырырга;

1.8. 7 нче номерлы кушымтада:

1.8.1. «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең эчтәлеге» графасының 2.6 пунктында «Торак-коммуналь хуҗалыгы идарәче компаниядән яисә Торак милекчеләре ширкәтеннән йорт (фатирлар) кенәгәсеннән өземтә» сүзләрен «Яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында мәгълүматлар яисә торак урыннан файдалану хокукын яки торак урынына милек хокукын раслый торган документ,» сүзләренә алмаштырырга;

1.8.2. 3.3.1 пунктта «йорт (фатирлар) кенәгәсеннән өземтәләр» сүзләрен «яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында мәгълүматлар яисә торак урыннан файдалану хокукын яки торак урынына милек хокукын раслый торган документ» сүзләренә алмаштырырга;

1.9. 4 нче номерлы кушымтада:

1.9.1. «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең эчтәлеге» графасының 2.6 пунктында «- рөхсәт бирелә торган муниципаль районга каравын раслый торган, эшкә сәләтсез кешенең теркәлү урыны буенча йорт кенәгәсеннән өземтә; - хосусыйлаштырылырга тиешле торак урынның йорт кенәгәсеннән (архив) өземтә һәм шәхси финанс счеты» сүзләрен «- яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында мәгълүматлар яисә торак урыннан файдалану хокукын яки торак урынына милек хокукын раслый торган документ» сүзләренә алмаштырырга;

1.9.2. 3.3.2 пунктта «- рөхсәт бирелә торган муниципаль районга каравын раслый торган, суд тарафыннан эшкә сәләтсез яки эшкә сәләтләре чикле дип танылган гражданинның теркәлү урыны буенча йорт кенәгәсеннән өземтә; -

хосусыйлаштырылырга тиешле торак урынның йорт кенәгәсеннән (архив) өземтә һәм шәхси финанс счеты» сүзләрен «- яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында мәгълүматлар яисә торак урыннан файдалану хокукын яки торак урынына милек хокукын раслый торган документ» сүзләренә алмаштырырга;

1.10. 8 нче номерлы кушымтада:

1.10.1. 1.3 пунктта «Опека һәм попечительлек органының кабул итү графигы: дүшәмбе – 14.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, чәршәмбе, пәнҗешәмбе – 9.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр» сүзләрен «Опека һәм попечительлек органнары шимбә, якшәмбе һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәреннән кала көн саен эшли. Кабул итү графигы опека һәм попечительлек органының эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

1.10.2. «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең эчтәлеге» графасының 2.5 пунктындагы 4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«4. Чит дәүләтнең вәкаләтле органнары тарафыннан бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәве турында таныклыкның күчермәсе һәм аның нотариуста таныкланган рус теленә тәрҗемәсе»;

1.10.3. «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең эчтәлеге» графасының 2.6 пунктында «- теркәлү урыны буенча йорт кенәгәсеннән өземтә һәм шәхси финанс счеты» сүзләрен «- яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында мәгълүматлар яисә торак урыннан файдалану хокукын яки торак урынына милек хокукын раслый торган документ» сүзләренә алмаштырырга;

1.11. 9 нчы номерлы кушымтада «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең эчтәлеге» графасының 2.6 пунктында һәм 3.3.2 пунктында «- яшәү урыныннан йорт (фатирлар) кенәгәсеннән өземтә яисә торак урыннан файдалану хокукын яки торак урынына милек хокукын раслый торган башка документ һәм яшәү урыныннан шәхси финанс счеты күчермәсе» сүзләрен «- яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында мәгълүматлар яисә торак

урыннан файдалану хокукын яки торак урынына милек хокукын раслый торган документ» сүзләренә алмаштырырга;

1.12. 10 нчы номерлы кушымтада:

1.12.1. 1.3 пунктта «эшкә сәләтсез гражданинның теркәлү урыны буенча» сүзләрен «гариза бирүченең яшәү урыны буенча» сүзләренә алмаштырырга;

1.12.2. «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең эчтәлеге» графасының 2.6 пунктында «- яшәү урыныннан йорт (фатирлар) кенәгәсеннән өземтә яисә торак урыннан файдалану хокукын яки торак урынына милек хокукын раслый торган башка документ; - яшәү урыныннан шәхси финанс счеты күчермәсе» сүзләрен «- яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында мәгълүматлар яисә торак урыннан файдалану хокукын яки торак урынына милек хокукын раслый торган документ» сүзләренә алмаштырырга;

1.12.3. 3.3.2 пунктта «- яшәү урыныннан йорт (фатирлар) кенәгәсеннән өземтә яисә торак урыннан файдалану хокукын яки торак урынына милек хокукын раслый торган башка документ һәм яшәү урыныннан шәхси счет күчермәсе» сүзләрен «- яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында мәгълүматлар яисә торак урыннан файдалану хокукын яки торак урынына милек хокукын раслый торган документ» сүзләренә алмаштырырга;

1.13. 12 нче номерлы кушымтада:

1.13.1. «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең эчтәлеге» графасының 2.6 пунктында «- рөхсәт бирелә торган муниципаль районга каравын раслый торган, эшкә сәләтсез кешенең теркәлү урыны буенча йорт кенәгәсеннән өземтә; - бирелә торган торак мәйданының йорт кенәгәсеннән өземтә, шәхси финанс счеты» сүзләрен «- яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында мәгълүматлар яисә торак урыннан файдалану хокукын яки торак урынына милек хокукын раслый торган документ» сүзләренә алмаштырырга;

1.13.2. 3.3.2 пунктта «- яшәү урыныннан йорт (фатирлар) кенәгәсеннән өземтә яисә торак урыннан файдалану хокукын яки торак урынына милек хокукын раслый торган башка документ; - сату урыныннан торак мәйданының

шәхси финанс счетлары һәм йорт кенәгәсеннән өземтә» сүзләрен «- яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында мәгълүматлар яисә торак урыннан файдалану хокукын яки торак урынына милек хокукын раслый торган документ» сүзләренә алмаштырырга;

1.14. 13 нче номерлы кушымтада:

1.14.1. «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең эчтәлеге» графасының 2.6 пунктында «- рөхсәт бирелә торган муниципаль районга каравын раслый торган, эшкә сәләтсез кешенең теркәлү урыны буенча йорт кенәгәсеннән өземтә» сүзләрен «- яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында мәгълүматлар яисә торак урыннан файдалану хокукын яки торак урынына милек хокукын раслый торган документ» сүзләренә алмаштырырга;

1.14.2. 3.3.2 пунктта «кредит акчаларыннан файдаланып торак сатып алуга һәм аны залогка (ипотекага) тапшыруга рөхсәт бирелә торган муниципаль районга каравын раслый торган, тәрбиядәге баланың теркәлү урыны буенча йорт (фатирлар) кенәгәсеннән һәм шәхси финанс счетыннан өземтәләр.» сүзләрен «яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында мәгълүматлар яисә торак урыннан файдалану хокукын яки торак урынына милек хокукын раслый торган документ,» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең документлары һәм хокукый актлары җыентыгында бастырып чыгарырга һәм аны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче Р.Г.Гафаров**